ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
*РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН*
ул.Кооперативная, д. 22, с.Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

*ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ*
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Утар-Аты авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**24 сентябрь 2018 ел.** **№ 30**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

"2019 елда Утар-Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

| | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге | -торак пунктларда вак таш сатып алу, җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл катламнарын тигезләү һәм асфальт түшәү;:<br>Утар Аты авылы<br>9 Май ур.<br>Совет урамы<br>Комсомол урамы<br>Мәктәп урамы<br>Кооператив ур.,<br>Субаш Аты авылы<br>Кооператив ур.<br>Яңа урам<br>9 Май ур.<br>Тарлау ур.,<br>Орнашбаш авылы<br>Мичурин ур. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Яшел урам<br>Механизаторлар урамы<br>Тукай урамы<br>Клуб урамы<br>Яшьләр урамы<br>Комсомол урамы,<br>Югары Аты авылы<br>Кооператив ур.<br>Комсомол урамы<br>Мәктәп урамы,<br>Иске Җөлбә авылы<br>Үзәк ур.<br>9 Май ур.,<br>Кушлавыч авылы<br>8 Март ур. ;<br>- Орнашбаш авылындагы Яшьләр һәм Комсомол урамнары кисешкән урында «Орнаш» елгасы аша күперне ремонтлау. |
| 2 | Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру | - Орнашбаш т. п. Тукай урамы буенча елга аша җәяүлеләр кичү юлын ремонтлау буенча материаллар сатып алу һәм эшләрне тәмамлау;<br>- материал алу һәм үткәрү<br>Субаш Аты, Орнашбаш авылларында чишмә төзекләндерү эшләре; |
| 3 | Җирлек торак пунктларында беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү: | -Утар Аты, Орнашбаш авылларында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру (һәр торак пунктка берәр);<br>-Утар Аты, Орнашбаш, Югары Аты, Субаш Аты, Иске Җөлбә, Кушлавыч авылларында (һәр торак пунктның берәрсе) янгын мотопомпалары сатып алу. |
| | Күмү урыннарын карап тоту | - Иске Җөлбә, Кушлавыч авыллары зиратлары коймаларын төзекләндерү һәм материал алу;;<br>- Кушлавыч авылы зиратына чүп җыю өчен контейнер сатып алу; |
| | Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру: | - Субаш-Аты авылында материал сатып алу һәм кое ремонтлау эшләре үткәрү ; |

Экономияләнгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

Әйе юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Арча районы, Утар Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт; ТР, Арча районы, Орнашбаш авылы, Яшьләр урамы, 6 йорт; ТР, Арча районы, Кушлавыч авылы, Тукай урамы, 1

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы И.И.Гайнуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УТАР-АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 16090 2653